*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 48**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Иренләшкән сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [и];
   ә) [ы];
   б) [о];
   в) [ә].

2. Сүзнең иҗек калыплары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   *яфраклар*
   а) СТ-ТСТ-ТСТ;
   ә) ТСТ-ТСТ-ТСТ;
   б) С-ТТСТ-ТСТ;
   в) ТТ-ТСТ-ТСТ.

3. Күчерелмә мәгънәдә килгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *авыр сумка*;
   ә) *авыр йөк*;
   б) *авыр таш*;
   в) *авыр эш.*

4. Тарихи сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *планшет*;
   ә) *алпавыт*;
   б) *угры*;
   в) *музей.*

5. Сүзнең тамыры дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   *күлмәкләрем*
   а) *күлмәк*;
   ә) *күл*;
   б) *мәк*;
   в) *күлмәкләр*.

6. Җөмләдәге затланышсыз фигыльләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ай да, болытларга төренеп, йокларга яткан.* (Фәнис Яруллин)

а) *яткан*;
ә) *төренеп, йокларга, яткан*;
б) *төренеп, йокларга*;
в) *ай, болытларга*.

7. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

***Уңган** кулында туфрак алтынга әйләнә*. (Мәкаль)

а) сыйфат;
ә) исем;
б) исем фигыль;
в) исемләшкән сыйфат фигыль.

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Эшләгән туңмас, эшләмәгән уңмас*. (Мәкаль)

а) хикәя;
ә) сорау;
б) боеру;
в) тойгылы.

## II. Теоретик бирем.

Күпнокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(6 балл)**

*ь, ъ, ң тартыклары* **..............** *хәрефтән язылмый. Омонимнар – бертөрле әйтелеп,* **.............** *мәгънә белдерә торган сүзләр. Бәйләгеч кушымчалар сүз* **....................** *килә. Боерык, хикәя һәм* **.................** *фигыльләр затланышлы фигыльләр дип атала. Бәйлекләр бер сүзне икенче сүз белән* **....................** *өчен кулланыла. Җөмләдәге сүзләр арасында* **..................** *һәм ияртүле бәйләнеш була.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(16 балл)**

*Лебеди*

*Однажды я увидел на озере двух белых птиц. Это были лебеди. Моя бабушка сказала, что они плавают здесь уже больше двух недель. Значит, им понравилось это место. Они хотят здесь поселиться.*

*Я сделал для птиц плавающую кормушку. Насыпал в неё зерно, мочёный хлеб. Лебеди долго не ршались приблизиться к кормушке. Но однажды один из них подплыл и взял хлеб. Постепенно лебеди привыкли ко мне. Они брали угощение прямо из рук.* («Яшь натуралист» журналыннан)

2. Сезнең җимлек ясаганыгыз бармы? Җимлек ни өчен кирәк, һәм аны ничек ясарга? Шул хакта фикерләрегезне 10 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(10 балл)**